Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Прибой посёлыгында 2024 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**18 ноябрь 2023ел** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» нигезендә, 2023 елның 16 ноябрендә 09 сәгать 30 минутта узган халык җыены нәтиҗәләре буенча 2024 елда Норлат авыл җирлеге торак пункты, Прибой посёлогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш, хәрби бурычны үтәгәндә имгәнгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ булган һәр кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертү буенча һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешу турында гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1) яр буе урамындагы юлны, Прибой бистәсенә керү юлын вак таш белән каплау .

2) торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 25 гражданин кертелгән, җыенында катнашучылар гражданнар саны 20 кеше, бу 80% тәшкил итә.

Халык җыенында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 20 кеше тавыш бирде, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең торак пунктында Прибой посёлогында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Норлат авыл җирлеге торак пункты, Прибой посёлогында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш, хәрби бурычны үтәгәндә имгәнгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ

булган һәр кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында» гражданнар җыены беркетмәсен гамәлдә дип танырга:

1) яр буе урамындагы юлны, Прибой бистәсенә керү юлын вак таш белән каплау .

2) торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Арьягы»үзәге бинасы) адреслары буенча кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Норлат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Саттаров И.М.